**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422701, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Высокая Гора , ул. Б.Красная, д. 113А

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422701, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авылы, Зур Кызыл ур., 113А йорт

тел./факс 8(84365) 74-7-79 e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**17.12.2024г.** **№ 416**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Уставы, Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү тора.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

Биектау авыл җирлеге башлыгы А. А. Хәбибуллин